ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.04.2020 г. Заинск № 192

**«Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» программасын гамәлгә ашыруны контролдә тоту комиссиясе турында нигезләмәне раслау хакында**

"Авыл территорияләрен комплекслы үстерү" Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында" 2019 елның 31 маендагы 696 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» программасын гамәлгә ашыруны контрольдә тоту комиссиясе турында нигезләмәне расларга (кушымта).
2. «Авыл җирлегендә яшәүче яшь гаиләләрне һәм яшь белгечләрне торак белән тәэмин итү» программасын гамәлгә ашыруны контролдә тоту комиссиясе турында нигезләмәне раслау хакында» 2007 елның 14 декабрендәге 1793 номерлы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында http://zainsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http:/pravo.tatarstan.ru/ урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Н.А. Нифатовка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф.Хафизов**

Юрист
С.А.Филюшина
7 07 75

КУШЫМТА
Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Башкарма комитетының
«30» 04. 2020 ел
192 номерлы карары
белән расланган.

**«Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» программасын гамәлгә ашыруны контрольдә тоту комиссиясе турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1 «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» программасын гамәлгә ашыруны контрольдә тоту буенча комиссия (алга таба - комиссия) Башкарма комитет җитәкчесе карары белән авыл җирендә яшәүче гражданнарга торак төзүдә (сатып алуда) ярдәм итү максатыннан, Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты бүлекләре, идарәләре, территориаль идарәләр, дәүләт органнары вәкилләреннән төзелә.

1.2. Комиссия әгъзалары аның эшендә җәмәгатьчелек тәртибендә катнаша.

1.3. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, 2004 елның 29 декабрендәге 188-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Торак кодексына (06.02.2020 редакциясендә), "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 июнендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга (27.12.2019 ел редакциясендә), «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, "Авыл территорияләрен комплекслы үстерү" Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында" 2019 елның 31 маендагы 696 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, 2014 елның 24 июнендәге 385 номерлы "Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына, әлеге нигезләмәгә һәм Россия Федерациясенең һәм Тататарстан Республикасының башка норматив хокукый актларына нигезләнеп эш итә.

1.4. Комиссия утырышлары зарурлыктан чыгып үткәрелә, ләкин кварталга 1 мәртәбәдән дә ким түгел, комиссия әгъзаларының кимендә 1/2 өлеше катнашса, утырыш хокуклы дип санала.

1.5. Комиссияне үткәрү датасын комиссия рәисе билгели, ә ул булмаганда - комиссия рәисе урынбасары.

1.6. Комиссия карарлары гади юл белән - тавыш бирүдә катнашучыларның күпчелеге тарафыннан ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

1.7. Комиссия беркетмәләренә һәм карарларына комиссиянең барлык әгъзалары имза сала һәм комиссия рәисе тарафыннан раслана.

## II. Комиссиянең функцияләре

2.1. Авылда яшәүче һәм эшләүче гражданнардан кергән торак шартларын яхшырту программасында катнашучылар составына кертү турында гаризаларны карый һәм гражданнарны чиратка кую турында карарлар кабул итә.
2.2. Торак шартларын яхшырту программасында катнашучылар составына кертү мөмкин булмаган очракта, баш тартуның нигезле сәбәпләре турында хәбәр итә.
2.3. Үз эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итүне оештыра.

## III. Комиссиянең хокуклары

3.1. Үзенә йөкләнгән вазыйфаларны башкару өчен комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:
- гражданнарга торак төзүдә (сатып алуда) ярдәм күрсәтүдә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелгән акчалардан файдалануны контрольдә тотуны гамәлгә ашырырга;
- торак төзүдә (сатып алуда) гражданнарга ярдәм итү мәсьәләләре буенча комиссия әгъзаларын, предприятие, учреждение җитәкчеләрен утырышта тыңларга.
- үз функцияләрен башкару өчен кирәкле мәгълүматны соратырга һәм алырга;
- комиссия, әгәр бу мәгълүмат займ бүлеп бирү турында мәсьәләне объектив карау өчен таләп ителә икән, гариза бирүчедән өстәмә мәгълүмат соратып алырга (мөрәҗәгать итүченең үзенең, аның гаилә әгъзаларының матди хәле, яшәү шартлары турында).

## IV. Комиссиянең эшчәнлек срогы

4.1. Комиссия үз эшчәнлеген Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән тәмамлый.